**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

422725, ТР Биектау районы, Олы Битаман авылы, Мәскәү ур. 2,
Тел./факс: +7(84365) 62-8-47,
e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**СОВЕТ**
**БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422725, Высокогорский район РТ,
с.Большой Битаман, ул.Московская, 2,
Тел./факс: +7(84365) 62-8-47,
e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**13 февраль 2015 ел** **№ 152**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Олы Битаман авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында " 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә (редакциядә) Район Уставын РФ Конституциясенә, федераль законнарга һәм ТР Конституциясенә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 86 статьясындагы 3 өлешенә, Олы Битаман авыл җирлеге Советы тарафыннан район Уставын Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында төзелде.

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 10.12.2014 ел, №144 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 33 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктына "җирлек" сүзеннән соң «җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплексны үстерү, җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программалары» сүзләрен өстәргә;

2) 71 статьяның 8 өлешендәге 6 абзацын түбәндәге эчтәлекле итәргә:

« - Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча җирлекнең норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару көне дип аларның тулы текстын "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" беренче урнаштыру (бастырып чыгару) тамгасы белән беренче бастырып чыгару мәҗбүри санала .PRAVO.TATARSTAN.RU;

3) 79 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек бюджеты проектларын төзү нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган нигезләмәләре;

бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

Россия Федерациясе таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре;

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

дәүләт (муниципаль) программалары (дәүләт (муниципаль) программалары проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

2. Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Олы Битаман авыл җирлеге башлыгы Р.А.Галимзянова